РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.12.2019 № 1724-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 30 гыйнварындагы 78-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Саба районы прокуратурасының 2019 елның 02 апрелендәге 02-08-02-43-2019 номерлы протестын карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлекнең технологик карталарын карау һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 елның 30 гыйнварындагы 78-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.** 1.2 пунктның 4 абзацын “, шулай ук, федераль законнарда, җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм, мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта, җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә, җирле үзидарә органнарының башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашуга хокуклары (күрсәтелгән Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаган) чикләрендә җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә күрсәтелгән Федераль законда каралган хокуклары чикләрендә башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары компетенцияләреннән төшереп калдырмаган һәм мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта, җирле үзидарә органнары хокуклары чикләрендә” сүзләре белән тулыландырырга.

**3**. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов